РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
СОРОК-САЙДАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫК-САДАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 21 маендагы 82-1 номерлы

Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге
Советы 2018 елның 03 сентябрендәге
54-3 нче номерлы карары белән расланган
«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кырык-Садак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын үткәрү әзерлек тәртибе турындагы
Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1 статьясын, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьсын гамәлгә ашыру максатында, Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрү әзерлек тәртибе турындагы Нигезләмә»гә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- нигезләмәнең 1.6 пунктының 7 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: «Җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатыннан, шулай ук яңа төзелгән җирлектә дә, әгәр сайлау хокукына ия аның халкы саны 300 кешедән дә артмаган булса, яңа төзелгән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;»;

- нигезләмәнең 3.5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: «Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашуда хокуклы. Торак пунктта бер үк вакытта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пунктка кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәр.елә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Халык җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Кырык-Садак авыл җирлеге башлыгы
ТР Буа муниципаль районы
Кырык-Садак авыл җирлеге Советы рәисе В.Ф. Шагиева